**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Шәрләрәмә авыл җирлегенең Сөлек авылы торак пунктында
2022 елда үзара салым кертү турында

**2021 елның 18 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенең Сөлек авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2022 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Сөлек авылы территориясендә I төркем инвалидларыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 350 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:
- Сөлек авылында кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту;
-МТЗ-320,4 махсус техникасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, машина йөртүчегә хезмәт өчен түләү);
- бәйрәмнәрне үткәрү өчен бүләкләр (Өлкәннәр көне, Инвалидлар көне, 9 Май, Сабантуй);
- Ветераннар яшэгэн йортларга мемориаль такталар сатып алу;
- Сөлек авылында зират территориясен эйлэндеру очен материаллар сатып алу.

3. Әлеге карарны Шәрләрәмә авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Шәрләрәмә авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Н.Н.Хуҗина